Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.03.2023 ел Менделеевск ш. №122

Җир кишәрлеген файдалануның
шартлыча рөхсәт ителгән төренә
рөхсәт бирү турындагы карар проекты
буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Россия Федерациясендә үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 июнендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты,

К А Р А Р  Б И Р Ә:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының административ бинасында 2023 елның 03 апрелендә 16 сәгатьтә Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 йорт адресы буенча актлар залында, кадастр номеры 16:27:110144:381булган Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Менделеевск шәһәре адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга (җир кишәрлеген куллануның рөхсәт ителгән төрен «территорияне төзекләндерү» дән «автомобильләрне ремонтлау»га үзгәртү)

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

Искаков А.Ф. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары вазифаларын башкаручы, комиссия рәисе;

Готин Ю.А. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесе башлыгы;

Хәбиров Р.З. - Татарстан Республикасы «Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы хезмәте архитекторы;

Антоновская Н.И. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча).

3.2023 елның 2 мартыннан 2023 елның 3 апреленә кадәрге чорда Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 йорт (5 кат) адресы буенча «Менделеевск муниципаль районының "Инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы хезмәте бүлегендә җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча материаллар экспозициясен оештырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423650, Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 йорт (Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының "Инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автономияле учреждениесенең баш архитекторы исеменә).

5.«Интернет» челтәрендә Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://Mendeleevsk.tatar.ru/ урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Искаковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Килештерелде

Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

Башкаручы Хәбиров Р.З.
8(85549)2-01-99